# 7 нче сыйныфта «Теркәгечләрнең дөрес язылышы» темасын өйрәнү

Казан шәһәре Совет районы
175нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Зарипова А.Ә.

# Теркәгечләр

- тезүче
  - җыючы
    - Һәм(да, дә, та, тә), вә, янә, тагы(н), ни... ни
  - каршы куючы
    - ләкин, әмма, тик, фәкать, бәлки, ә, бары
  - бүлүче
    - я, яки, яисә
- иярткүче
  - чөнки, гүя, ки, гүяки, әгәр, гәрчә

# *Сайланма диктант*

| *җыючы* | *каршы куючы* | *бүлүче* | *ияртүче* |
|---|---|---|---|
| | | | |

# *Сайланма диктант*

| *җыючы* | *каршы куючы* | *бүлүче* | *ияртүче* |
|---|---|---|---|
| һәм | ләкин, әмма | - | гүя, чөнки |

# Уйлап карагыз

**Да –дә, та – тә ?**

# Моңлы тел

Безнең телебез – бик моңлы да, ягымлы да тел. Борынгы халык көйләрен тыңлаганда, моң, безнең күңелләребезне айкап, тирән уйларга, кичерешләргә сала. Шушы моң халыкның хәтере кылларына кагыла да үткәннәрне бүгенге белән тоташтыра.

Телнең матурлыгы, моңлылыгы композиторларга һәм шагыйрьләргә генә түгел, барыбызга да кирәк. Матур итеп сөйләшә белгән кеше матур итеп уйлый да белә, ә андый кеше матур эшләргә омтыла.

(Фәнис Яруллиннан)

# Җавап бирегез

**Да – дә, та –тә ?**

**кушымча** **теркәгеч** **кисәкчә**

# Биремнәр

- Да – дә, та –тә теркәгечләрен, кисәкчәләрен, кушымчаларын кулланып, 3 җөмлә төзеп языгыз
- Да –дә, та – тә теркәгечләрен кертеп, ике җөмлә төзегез.
- -да, – дә, -та, –тә кушымчалары яки кисәкчәләре ярдәмендә җөмлә языгыз.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ
# (1886-1913)



**Сөй гомерне, сөй халыкны,**
**сөй халыкның дөньясын,**

**Без үләрбез, билгеле,**
**тик үкенечкә калмасын**

# *Өзекләр кайсы әсәрләрдән?*

***И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә - эш,***
***Эш агачы һәрвакыт (та) бик юмарт – китрер җимеш.***

**"Эшкә өндәү"**

**Инде мин әкрен генә килдем (дә) кердем басмага**
**Җен оныткан, ахыры, - калган тарагы басма (да)**

**"Су анасы"**

***Эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчен (дә), уй (да) мин;***
***Ичмасам иптәш (тә) юк ич, тик икәү без: уй (да) мин.***

***"Пар ат"***

**Урманында кып – кызыл кура җиләк (тә), җир җиләк;**
**Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк**

***"Шүрәле"***